КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 август № 885

г.Казань

Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча (дисциплина – акватлон) Россия чемпионатын һәм беренчелеген уздырганда су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча (дисциплина – акватлон) Россия чемпионатын һәм беренчелеген уздырганда кешеләрнең тормыш куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларындаТатарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Казансу елгасында Кремль дамбасыннан алып «Компрессор күпер» өченче транспорт дамбасына кадәр участокта аз үлчәмле, йөрүче, спорт-җилкәнле судноларны куллануны тыярга:

2022 елның 26 августында 15.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр,

2022 елның 27 августында 7.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;

әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән судлардан файдалануны тыю триатлон буенча (дисциплина - акватлон) Россия чемпионатын һәм беренчелеген әзерләү һәм уздыру өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмый.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

әлеге карар белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында күрсәтелгән участокларда тиешле көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

кертелә торган тыю турында халыкка хәбәр итү эшен оештырырга, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша да.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә әлеге карарда билгеләнгән тыюны үтәү максатларында тиешле көчләрнең һәм чараларның кизү торуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин